МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.04.2023 Казан ш. № 11-28

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.05.2016 ел, № 11-60 боерыгы белән расланган Дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к  б и р ә м:

“Дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиясе турында” Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 25.05.2016 ел,№ 11-60 боерыгы белән расланган Дәүләти гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 21.03.2018 ел, № 11-35 боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләрне (кушымта итеп бирелә) расларга.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 07.04.2023 № 11-28 боерыгы белән расланды

Дәүләти граждандлык хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр бәрелешен җайга салу буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы комиссиясе турында нигезләмәгә кертелә торган үзгәрешләр

1. 2.2 пунктның “б” пунктчасында “коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президенты Идарәсе вәкиле” дигән сүзләрне “коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Рәисе Идарәсе вәкиле”дигән сүзләргә алыштырырга.

2. 2.3 пунктның “а” пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет вәкиле;».

3. Второе предложение пункта 3.4.2 пунктның икенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Мәгълүмат алу өчен министрлык тарафыннан дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынулы оешмаларга, шул исәптән коррупциягә каршы көрәш өлкәсендәге “Посейдон” дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланып, запрослар җибәрелергә мөмкин”.